Татарча التترية

Зәкәт ике төргә бүленә

Мөстәһәб (ихтыярый)– ул чын күңелдән Аллаһ ризалыгы өчен малыңны сарыф итү.

Фарыз

Фарыз булган зәкәт икегә бүленә:

Тән зәкәте(фитр сәдакасы)

бу төр сәдака барлык мөселманга да үәҗиб булып тора, зурысына да, кечесенә дә, ир-атка да, хатын-кызга да, колга да, иреклегә дә.

Мал зәкәте

ул малыңның шәригать билгеләгән бер өлешен чыгарып, билгеләгән төркемгә сарыф итеп, Аллаһка гыйбадәт кылу. Бу Исламның өченче әркәне булып тора

һәм ул дүрт төргә бүленә:

1 **Алтын-көмештән**

акчадан һәм аларны алмаштыра торган башка нәрсәләрдән зәкәт, акчаның күләме 85 грамм алтын бәясенә, я инде 595 грамм көмеш бәясенә җитәргә тиеш.

2 **Көтүлектә йөрүче терлек**

тулысынча, я инде күп вакытын көтүлектә уздыручы дөя, сыер, сарык кебек мал-туар керә.

3 **Җирдән үсеп**

чыгучы бөртек-ярма.

4 **Сату-алу товары**

сәүдәдә булган барлык товар да керә.

Зәкәт бирелергә тиеш булган кешеләр:

1 **Фәкыйрьләр** — бернәрсәсе дә булмаган, я инде кайбер нәрсәсе генә булган кешеләр керә.

2 **Мескеннәр** — алар яшәр өчен кирәк яракның яртысын, я инде күбрәген табалар. Мисал өчен ел дәверендә яшәр өчен 200 мең акча кирәк. Фәкыйрь ел буена 100 мең дә, я инде бөтенләй бернәрсә дә таба алмый. Ә мескеннең еллык кереше 100 мең, я инде күбрәк, ләкин 200 меңгә тулмый. Аларның икесенә дә шушы җитмәгән күләм мал бирелә.

3 **Зәкәт эшчеләре** — хөкемәт билгеләгән зәкәтне җыючылар, саклаучылар, бүлүчеләр керә. Һәм аларның Фәкыйрь, яисә мескен булулары шарт булып тормый.

4 **Йөрәкләрне йомшартыр өчен** — бу кешеләрнең Исламга керүен теләп, я инде кемнеңдер явызлыгыннан сакланыр өчен, я инде иманны күтәрер өчен бирелгән мал.

5 **Мөселманнарны азат итү** — а) - Үз-үзен коллыктан сатып алырга теләүче колга, б) - колны азат итүгә, в) - мөселманны әсирлектән азат итүдә.

6 **Әҗәтен кайтара алмаучыга** — шул әҗәтен капларлык мал бирелә.

7 **Аллаһ юлында** — Аллаһ юлында булучыларга

8 **Юлчыга** — юлда булып, юлын дәвам итергә акчасы булмаган мөсәфиргә. Мондый кешегә өенә кайтып җитәрлек мал бирелә.